

21 февраль – Халыкара туган тел коне. Бvген галимнәр доньяда жиде менгә якын тел бар, дип саныйлар. Шуларнын сиксән оче кин таралган. Ә оч йоз сиксән оч тел ботенләй юкка чыгарга момкин. Татар теле –- ЮНЕСКО тарафыннан ботендонья халыкара аралашу теле дип саналган 14 телнен берсе. Бу – туган телебез белән горурланырлык моһим фактор.
ЮНЕСКО тарафыннан игълан ителгән әлеге халыкара бәйрәм доньядагы телләрне саклау, аларны киләчәк буынга исән-имин житкерv максаты белән оештырылган. Мордовия кvләмендә дә татар теле янгырый; милли мәктәпләрдә татар телен фән буларак ойрәнәбез, ана багышлап кичәләр, онлайн-форматта конкурслар, олимпиадалар оештырыла һәм башка чаралар vтә.       Туган тел – ул акыл садыгы дип юкка гына әйтмиләр. Хәзерге заманда кvпчелегебез ким дигәндә 2-3 телне камил белә. Һәр халыкнын теле vзенчәлекле, кvп телләр белv доньяга карашны кинәйтә, торле милләт халкынын мәдәниятен тирәнрәк белергә ярдәм итә. Ләкин туган тел ул бер генә. Безнен телебез - татар теле. Шуна кvрә һәр татар кешесе vз теленә хормәт белән карарга тиеш. Татар халык мәкале: «Туган телне кадерләгән халык кадерле булыр», - ди. Туган телләребезне саклыйк, яклыйк, чонки милләтнен яшәешендә туган тел ин моһим урыннарнын берсен алып тора. Һәм бvген бездә бер теләк: Мордовия яшьләребез кvбрәк татар телендә сойләшсә иделәр! Телебезне балаларыбызга һәм оныкларыбызга тапшыру – безнен топ бурычыбыз.

**Наилә НАСЫРОВА**